СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

# КАРАР

2020 нче елның 01 июне № 83/1

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләр өлешен) тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы советына Яңа Борындык авыл җирлеге советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирлекнең генераль планнарын раслау, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлекләрне шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге советына кабул иткән очракта: әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы белән килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дигән карарга килергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге Советының 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борынды авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгару, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Яңа Борындык авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Ранцев